**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6903**
**20.10.2021**

Башкарма комитетның «Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2021 елның 19 гыйнварындагы 214 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Гражданнарның аерым категорияләре өчен автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү турында» 2021 елның 19 гыйнварындагы 214 номерлы карарының 2 пунктына, «79 272,50» цифрларын «77 294,5» цифрларына алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов